ПРИНЯТО:
на педагогическом совете МАДОУ
Детский сад№14 «Сказка»
Протокол №1 от «27» августа 2018 г

УТВЕРЖДЕНО:
заведующий МАДОУ
«Детский сад№14 «Сказка»
___________Ф.Н.Якупова
введено приказом №101
от «03» сентября 2018 года

Пронумеровано и

# Рабочая программа
# игровой образовательной деятельности
# (кружок)
# «Играем в сказку»

## на 2018-2019 учебный год

Педагог дополнительного образования:
воспитатель по обучению детей татарскому языку
Рахимова Расима Гасымовна

# Аңлатма язуы

Федераль дәүләт таләпләре нигезендә төзелгән “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программа”сында “балаларны сәхнә сәнгатенә тарту, аларның артистлык сәләтләрен үстерү, сәхнәләштерү өчен, Идел буе халыкларының әкиятләрен, шигырьләрен, җыр-биюләрен файдалану, сәхнә сәнгатенә кызыксыну үстерү” бурычлары күрсәтелә. Әлбәттә, балаларны аралашырга өйрәтүдә, аларның сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үз-үзләрен тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүләрендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

Сәхнәләштерелгән уеннар, тәрбия чарасы буларак, балаларның шәхес булып формалашуына зур йогынты ясый, психик үсешенә ярдәм итә. Алай гына да түгел, алар нәниләрдә дуслык, гаделлек, зирәклек кебек сыйфатлар да тәрбияли, аларның игътибарын арттырырга, хәтерләрен үстерергә ярдәм итә. Уйнаганда, балаларның иҗат мөмкинлекләре ачыла, мөстәкыйльлекләре арта, оештыру сәләтләре үсә. Әлеге уеннар шулай ук нәниләрнең төрле яклап үсүен тәэмин итә, иҗади мөмкинлекләрен, хыялларын баета, фикер активлыкларын, зиһеннәрен үстерә.

Тәрбияче өчен сәхнәләштерелгән уен – балаларны яхшырак аңлау, аларга тагын да ныграк якынаю чарасы. Уен ярдәмендә тәрбияче оялчан, үз эченә бикләнгән балаларны да “уятырга” мөмкин. Уендагы текстка, җырга кушылып, ниндидер роль башкарып, балалар үз көчләренә ышанырга, эшләгән эшләренә бәя бирергә өйрәнә, аларда башкаларның хәленә керә белү, ярдәмләшү, игътибарлылык кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә.

Халкыбыз тарафыннан иҗат ителгән серле һәм мавыктыргыч әкиятләрне сәхнәләштереп уйнап, балалар уңай һәм тискәре сыйфатларны аерырга, әкият геройларының уй-хисләренә, эш-гамәлләренә дөрес бәя бирергә, мәрхәмәтле, рәхимле-шәфкатьле, ярдәмчел булырга өйрәнәләр. Әкият геройлары белән танышу аша аларның борчу-шатлыкларын, рухи халәтләрен аңларга өйрәнәләр, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, тормыш тәҗрибәсен үзләштерәләр.

Балалар шигырьләрне сәхнәләштереп уйнарга бик яраталар. Алар яңгырашлы рифмалы шигырьләрне тиз отып алалар, анда катнашучы персонажларның кичерешләренә бәйле рәвештә, интонацияләрен үзгәртеп, сәнгатьле итеп сөйлиләр. Шигырьләрне укыганда, балаларның игътибарын сурәтләү чараларына (чагыштырулар, тапкыр сүзләр, эпитетлар) юнәлтү, автор кулланган образлы әйтелмәләр матурлыгын күрсәтү, төшендерү мөһим.Болай эшләгәндә, нәниләрдә матур әдәбият әсәрләрен күңелең белән тою, сиземләү хисләре туа, эстетик тойгылар уяна, матур әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләнә.

Сабыйларның сөйләм телен үстерү, авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, фонематик ишетү сәләтләрен арттыру максатыннан, түгәрәк эшчәнлегендә, тизәйткечләрне, табигатькә, кош-кортларга эндәшләр һәм җор телле халкыбыз иҗат иткән башка әсәрләрне файдалану мөһим.

**Программаның максаты:** иҗади мөмкинлекләрен, сәләтләрен ачу; яшьтәшләре, әти-әниләре һәм башка кунаклар каршында чыгыш ясау мөмкинлеге бирү.

**Бурычлары:**

1. Балаларны театр сәнгатенә тарту; театр һәм театр һөнәрләре турында мәгълүмат бирү.

2. Уеннарны, шигырь һәм әкиятләрне сәхнәләштерү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. Сәхнәләштерелгән уен – гамәлләрдә катнашасы килү теләге булдыру.

3. Әсәр геройларының эчке кичерешләрен, эмоөиональ халәтен сиземләргә, аңларга һәм рольләрдә башка персонажлар белән үзара бәйләнешкә керергә өйрәтү.

4. Сәхнәләштерүнең сәнгати чараларын (гәүдә торышы, мимика, интонация, хәрәкәтләр) кулланырга өйрәтү.

5. Иҗади мөскәкыйльлек, эстетик зәвык тәрбияләү.

6. Образлар аша баланың күзаллау сәләтен, фантазиясен, сөйләм телен үстерү.

7. Уйналган рольләрне, спектакльләрне анализлау процессында фикер йөртү һәм бәяли белү күнекмәләрен формалаштыру.

8. Театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү.

**Билгеләнеше:**

План программа зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме өчен тәкъдим ителә. Түгәрәк атнага бер тапкыр көннең икенче яртысында үткәрелә. Түгәрәк эшенең дәвамлылыгы 25-30 минут тәшкил итә.

| *Атна (ай)* | Темасы | Бурычлар | Эш төрләре | Кулланылган әдәбият |
|---|---|---|---|---|
| ***Октябрь 1 нче атна*** | “Әкият” курчак театрында кунакта | Казан шәһәренең истәлекле урыннары белән таныштыруны дәвам итү; туган як турындагы белемнәрен киңәйтү; Л.Шагыйрьҗанның “Курчак театрында”шигырен уку | 1.”Әкият” курчак театрына сәяхәт” темасына презентация карау.<br>2.”Татар халкының тылсымлы әкиятләре – сәхнәдә!”темасына курчак театры әкиятләреннән өзекләр карау.<br>3.Әкият курчаклары турында сөйләшү.<br>4.”Чыпчыклар” дигән сулыш алу кунегуен өйрәнү. | 1.”Театральная деятельность в детском саду” китабы, 18 бит.<br>2.”Балачак аланы”китабы, 501 бит. |
| ***2 нче атна*** | Театрда эшләүче һөнәр ияләре | Балаларның театрда эшләүчеләр турында күзаллауларын баету; халык авыз иҗаты әсәрләре белән кызыксынуларын арттыру;(**к**) авазының дөрес әйтелешен ныгыту. | 1.Театрда эшләүче һөнәр ияләре: актёр, гримёр, костюмер, чәчтараш, парикмахер),декоратор һ.б.турында мәгълүмат бирү.<br>2.Грим ясауның ни өчен кирәклеген төшендерү. Грим ясап карау.<br>3.”Тау башында таллыкта тукраннар тукылдый” тел шомарткычын өйрәнү.<br>4.”Футбол” уенын уйнау. | 1.”Иң матур сүз” китабы, 362 бит.<br>2.”Иң гүзәл тел- туган тел” китабы, 41 бит. |
| ***3 нче атна*** | Бабай шалкан утырткан... | Халык авыз иҗаты әсәләре белән кызыксыну тәрбияләү; күзаллау һәм образлы фикерләү сәләтләрен үстерү; җырлау күнекмәләрен камилләштерү. | 1.”Табышмак әйтәм – җавабын тап” уенын уйнау (шалкан, эт, песи, тычкан турында табышмаклар әйтү).<br>2.”Шалкан”әкияте буенча эшләнгән мультфильм карау.<br>3.Әкият персонажларының уй-кичерешләре турында әңгәмә үткәрү.<br>4.Әкият ахырындагы җырны (“Безнең бакча”)өйрәтү. | 1.”Иң матур сүз” китабы,17 бит.<br>2..”Иң гүзәл тел- туган тел” китабы, 46 бит. |
| ***4 нче атна*** | “Шалкан” әкиятен сәхнәләштерергә әзерлек | Театраль чараларның үзенчәлекләрен аңларга өйрәтү; әкиятне сәхнәләштереп сөйли | 1.Театраль чаралар(яктылык, музыка, декорацияләр һ.б.) турында сөйләшү. | “Театр для малышей” китабы, 53-55 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | белү күнекмәләре бирү; роль сайлый белү осталыгын булдыру; кара-каршы сөйләшү культурасы формалаштыру. | 2.Рольләр билгеләү.<br>3.Кара-каршы сөйләшергә өйрәтү.<br>4.Тиешле интонация белән сөйләргә өйрәтү.<br>5.Җырның сүзләрен хәрәкәтләр белән җылап карау. | |
| ***Ноябрь 1 нче атна*** | “Шалкан” әкиятен сәхнәләштерергә әзерлек (дәвамы) | Персонажларның характерлы гамәлләрен охшатып уйнарга өйрәтү;сөйләмнең дөрес темпын булдыру; сүздәге авазларны ачык итеп әйтергә өйрәтүне дәвам итү. | 1.Сәхнәдә хәрәкәтләнергә өйрәтү.<br>2.Музыкага хәрәкәтләнергә өйрәтү.<br>3.Җырлы-биюле уенны өйрәнеп бетерү. | “Үз илемдә, үз телемдә” китабы, 148 – 151 битләр. |
| ***2 нче атна*** | “Шалкан” әкиятен сәхнәләштерергә әзерлек (дәвамы) | Әкият геройларының эмоциональ халәтен күрсәтә белергә өйрәтү; сәнгатьле сөйләм нигезләрен формалаштыру. | 1.”Серле капчык” уенын уйнау (а,ә) авазларын дөрес әйтү күнекмәсен ныгыту.<br>2.”Әйтеп бетер” уенын уйнау.<br>3.Сәнгатьле сөйләм күнегүләрен үтәү.<br>4.Сәхнәдә хәрәкәтләнергә өйрәтү. | 1.”Иң татлы тел-туган тел”китабы, 12-13 битләр.<br>2.Уйнап укый сабыйлар” китабы, 98 бит.<br>3.“Үз илемдә, үз телемдә” китабы, 148 – 151 битләр. |
| ***3 нче атна*** | “Шалкан” әкиятен сәхнәгә кую | Атрибутлардан, костюмнар һәм декорацияләрдән дөрес файдалану күнекмәләрен ныгыту; башкару осталыкларын камилләштерү; уйналган рольләрне анализлый, бәяли белү күнекмәләрен үстерү. | 1.Әкиятне кечкенәләр һәм уртанчылар төркеменә йөрүче балаларга күрсәтү.<br>2.Уйналган рольләрне анализлау. | 1.”Иң матур сүз” китабы,17 бит.<br>2.“Үз илемдә, үз телемдә” китабы, 148 бит. |
| ***4 нче атна*** | Рус халык әкияте “Теремкәй” | Балаларның сәхнә уеннары белән кызыксынуларын арттыру; әдәби әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли белү күнекмәләрен ныгыту; караган әсәр турында үз фикерләрен әйтә белергә өйрәтү. | 1.”Табышмак әйтәм-җавабын тап” уенын уйнау (әкият персонажлары турында табышмаклар әйтү).<br>2.”Теремкәй” әкияте буенча эшләнгән мультфильм карау.<br>3.Әкият персонажларының уй-кичерешләре турында әңгәмә үткәрү.<br>4.”Теремкәйдә кем яши”?сүзле уенын | 1.”Иң матур сүз” китабы, 26 бит.<br>2.”Иң татлы тел-туган тел”китабы, 248 бит. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | уйнау. | |
| ***Декабрь 1 нче атна*** | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерергә әзерлек | (**т**), (**р**) авазларын дөрес, ачык итеп әйтергә өйрәтү; рольгә керә белү, башкару осталыкларын үстерү; игътибарлылык һәм реакция тизлеге тәрбияләү. | 1.(**т**), (**р**) авазларын дөрес әйтү күнегүләрен эшләү.<br>2.Әкиятне эпизодларга бүлү.<br>3.1 нче эпизод (“Бу нинди теремкәй?”) буенча эш.<br>4.”Куллар-аяклар” уенын уйнау | 1.”Театральная деятельность в детском саду» китабы, 47 бит.<br>2.»Иң гүзәл тел- туган тел” китабы, 84 бит |
| ***2 нче атна*** | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерергә әзерлек (дәвамы) | Сүзләрне ачык, чиста һәм төгәл әйтүне камилләштерү; рольгә керә белү күнекмәләрен ныгыту;(р), (л) авазларының дөрес әйтелешен ныгыту; дикция күнекмәсен бирү. | 1.”Кайтаваз” сулыш алу уенын уйнау.<br>2.Рольләрне, вазифаларны бүлешү.<br>3.”Әбинең ишегалды” уенын(йорт кошлары турында) уйнау.<br>4.Тел шомарткычлар өйрәнү(ш), (с) авазларын дөрес әйтү күнекмәсен бирү:Ыш-ыш-ыш, безгә килде кыш”. | 1.”Театральная деятельность в детском саду» китабы, 52-53 битләр. |
| ***3 нче атна*** | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерергә әзерлек (дәвамы) | Ритм, хәрәкәт координацияләрен үстерү, хис-тойгыны ишарәләр белән күрсәтү күнекмәләре бирү; персонажларның кичерешләренә бәйле рәвештә, интонацияне үзгәртеп сөйләргә өйрәтү; иҗади мөмкинлекләрен арттыру. | 1.Санамыш өйрәнү.<br>2.2 нче (“Икәү яшәү күңеллерәк!), 3 нче (“Өчәү яшәү тагын да күңелле!), эпизодлар буенча эш.<br>3.”Кош-канаты белән, кеше дуслары белән көчле” мәкален өйрәтү. | 1.”Иң матур сүз” китабы, 26 бит.<br>2.”Театральная деятельность в детском саду» китабы, 56 бит. |
| ***4 нче атна*** | Яңа ел килә!.... | Балаларның эш һәм бәйрәм көннәре турындагы күзаллауларын үстерү; бәйрәм тантаналарына уңай мөнәсәбәт тәрбияләү; яшьтәшләрен һәм өлкәннәрне бәйрәм белән котлау, аларны сөендерәсе килү теләге тудыру. | 1.Р.Миңнуллинның “Чыршы әйләнәсендә” шигырен уку.<br>2.Яңа ел бәйрәме турында әңгәмә үткәрү.<br>3.”Кыш бабайга хат язабыз”. Балаларның Кыш бабайга теләкләре турында сөйләшү.<br>4.Ирекле кисеп ябыштыру эшчәнлеге: | 1.”Иң матур сүз” китабы, 336 бит.<br>2.”Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 194 бит. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | “Яңа ел бүләге”. | |
| ***Гыйнвар 3 нче атна*** | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерергә әзерлек (дәвамы) | Сөйләм аппаратын камилләштерү; интонацияне үзгәртеп сөйләү күнекмәләрен ныгыту. | 1.”Йоклыйсым килә” сулыш алу күнегүен эшләү.<br>2.”Яңа ел кунаклары” уенын уйнау.<br>3.”Нәрсә ул дуслык?” темасына әңгәмә үткәрү.<br>4.4 нче, 5 нче эпизодлар буенча эш. | 1.”Театральная деятельность в детском саду» китабы, 59 бит. |
| ***4 нче атна*** | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерергә әзерлек (дәвамы) | Балаларның сүзләрне дөрес, ачык итеп әйтә, хәрәкәтләрне төгәл күрсәтә белүләрен камилләштерү; бәйләнешле һәм сәнгатьле сөйләм сәләтләрен үстерү; игътибарлылыкларын арттыру. | “Паровоз” сулыш алу күнегүен эшләү.<br>2.”Сигналны тыңла”уенын уйнау.<br>3.Хәрәкәтләрне музыкага башкарырга өйрәтү.<br>4.Дикцияләрен яхшырту күнегүен эшләү. | “Иң матур сүз” китабы, 26 бит. |
| ***Февраль 1 нче атна*** | “Теремкәй” әкиятенең премьерасы | Рольләрне башкару күнекмәләрен (ишарә, мимика, хәрәкәтләр) ныгыту. | Спектакльне кечкенәләр төркеменә йөрүче балаларга кую. | “Иң матур сүз” китабы, 26 бит. |
| ***2 нче атна*** | Б.Рәхимовның “Әти бәйрәме көне” шигырен сәхнәләштерергә әзерлек | Кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерергә булышлык итү; әти кешегә хөрмәт, ихтирам хисләре тәрбияләү. | 1.Мәкальләр әйтү, мәгънәләре буенча фикер алышу.<br>2.Ил сакчылары көне турында әңгәмә үткәрү.<br>3.Шигырьне уку.<br>4. Шигырьнең эчтәлеге буенча сораулар һәм җаваплар бирү.<br>5.”Бу хәрби кем?” устерелешле уенын уйнау.<br>6.Шигырьне сәхнәләштереп сөйләргә өйрәтү. | 1.“Иң матур сүз” китабы, 338 бит.<br>2.”Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 231 бит. |
| ***3 нче атна*** | Б.Рәхимовның “Әти бәйрәме көне” шигырен сәхнәләштерергә әзерлек | Балаларның иҗади мөмкинлекләрен, сәләтләрен үстерү; яшьтәшләре һәм әти-әниләре алдында чыгыш ясаудан алган тәэсирләрен баету; | Шигырьне сәхнәләштереп уйнау | 1.“Иң матур сүз” китабы, 338 бит. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | этиләре белән горурлану хисләре тәрбияләү. | | |
| ***4 нче атна*** | Мин шигырьләр яратам! | Ф. Яруллинның “Өйдә калам”, Э.Мөэминованың “Җавап бир” шигырьләрен рольләргә бүлеп сөйләргә өйрәтү; шигырьләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләре бирү; шигырьләрнең эчтәлеген сүзләр, хәрәкәтләр, ишарәләр белән белдерергә өйрәтү. | 1.Шигырьләрне уку.<br>2.”Шигырьләргә исем куй” уенын (балаларның тәкъдимнәрен, фикерләрен тыңлау) уйнау.<br>3.”Мәкальне әйтеп бетер”уенын (әниләр турында) уйнау.<br>4. Шигырьләрне сәхнәләштереп сөйләү. | 1.1.“Иң матур сүз” китабы, 323 -324, 359 битләр.<br>2.”Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 94 бит. |
| ***Март 1 нче атна*** | Мин шигырьләр яратам! | Алдагы түгәрәктә укыган шигырьләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләрен ныгыту; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | Ф.Яруллинның “Өйдә калам”, Э.Мөэминованың “Җавап бир” шигырьләрен “Әниләр бәйрәме”ндә рольләргә бүлеп сөйләү. | “Иң матур сүз” китабы, 323-324 битләр. |
| ***2 нче атна*** | “Йомры икмәк” әкияте буенча өстәл театры | Өстәл театры курчакларын йөртү алымнарын өйрәтү; курчакларны йөрткәндә җырлау күнекмәләрен бирү. | 1.Тизәйткечләр өйрәтү: “Ша-ша, менә синң тамаша! Шә-шә-шә, су тулы шешә(ш) авазын дөрес әйтү күнекмәсе бирү.<br>2.Өстәл театры. | “Үз илемдә, үз телемдә” китабы, 144 бит. |
| ***3 нче атна*** | Венгр халык әкияте “Комсызлык бәласе” | Төрле эстетик чаралар (мимика, ишарә, интонация) кулланып, образларны гәүдәләндерергә өйрәтү; сөйләмнең дөрес темпын булдыру; сүздәге авазларны ачык итеп әйтергә өйрәтүне дәвам итү. | 1.Әкият буенча мультфильм карау.<br>2.Әкият персонажларының уй-кичерешләре турында әңгәмә үткәрү.<br>3.Рольләр бүлешү.<br>4.Кара-каршы сөйләшергә өйрәтү.<br>5. Тиешле интонация белән сөйләргә өйрәтү. | “Иң матур сүз” китабы, 71 бит. |
| ***4 нче атна*** | Венгр халык әкияте “Комсызлык бәласе” | Кара-каршы сөйләшергә өйрәтү. | 1.Сәхнәдә хәрәкәтләнергә өйрәтү.<br>2.Музыка уйнап торганда хәрәкәтләнергә өйрәтү. | “Иң матур сүз” китабы, 71 бит. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ***Апрель 1 нче атна*** | Венгр халык әкияте “Комсызлык бәласе”н сәхнәгә кую | Балаларның атрибутлардан, костюмнар һәм декорацияләрдән дөрес файдалану кунекмәләрен ныгыту; башкару осталыкларын камилләштерү. | 1.Әкиятне кечкенәләр һәм уртанчылар төркемендә йөрүче балаларга уйнау.<br>2.Уйналган рольләрне анализлау. | “Иң матур сүз” китабы, 71 бит. |
| ***2 нче атна*** | “Г.Тукай безнең күңелләрдә!...” | Балаларны Г.Тукайның күпкырлы иҗаты белән кызыксындыру, иҗатына ихтирам тәрбияләү. | 1.Г.Тукайның “Туган тел” җырын тыңлау.<br>2.Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты турында сөйләшү (слайдлар ярдәмендә).<br>3.”Кайсы әсәрдән икәнен бел” үстерелешле уенын уйнау. | “Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 118.272 битләр. |
| ***3 нче атна*** | Г.Тукайның “Бала белән күбәләк”, “Гали белән Кәҗә” шигырьләрен сәхнәләштерү. | Персонажларның кичерешләренә бәйле рәвештә, интонацияне үзгәртеп сөйләргә өйрәтү; иҗади мөмкинлекләрен арттыру. | 1.Күбәләк, кәҗә турында табышмаклар әйтү.<br>2.Шигырьләрне уку.<br>3.”Бала белән күбәләк”җырын тыңлау.<br>4.Мультфильмнар карау.<br>5.Шигырьләрне сәхнәләштерү. | “Туган телдә сөйләшәбез” китабы, 120 бит. |
| ***4 нче атна*** | Татар халык әкияте “Бүләк кемгә?” | Әкиятнең эчтәлеген хәтердә калдырырга ярдәм итү; текстның эчтәлеген өлешләп һәм тулысы белән сөйләргә өйрәтү;табигатьтәге сезонлы үзгәрешләрне, ел фасыллары белән бәйле хезмәт эшчәнлеген күрә, аңлый белергә өйрәтү. | 1.Ел фасыллары турында табышмаклар әйтү.<br>2.Әкият буенча эшләнгән презентация карау, эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү.<br>3.Рольләрне, вазифаларны бүлешү.<br>4.”Кояш һәм йолдызлар” хәрәкәтле уенын уйнау.<br>5.”Күрәзәче” устерелешле уенын уйнау. | 1.”Иң гүзәл тел-туган тел” китабы, 62-64 битләр.<br>2.”Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел” китабы, 310-312 битләр. |
| ***Май 1 нче атна*** | Татар халык әкияте “Бүләк кемгә?” | Балаларга авазларны дөрес, ачык итеп әйтергә өйрәтү; башкару күнекмәләрен(рольгә керә белү, дөрес хәрәкәтләр ясау)үстерү; игътибарлылык һәм реакция тизлеге | 1.Диалог формасында сәнгатьле итеп уйнап карау.<br>2.Дөрес интонация белән сөйләргә күнектерү.<br>3..Мимика, ишарәләр һәм гәүдә | 1.. “Иң гүзәл тел-туган тел” китабы, 62-64 битләр.<br>2.”Үз илемдә, үз телемдә” китабы, 117-127 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | тәрбияләү. | хәрәкәтләрен кабатлау. | |
| ***2 нче атна*** | Татар халык әкияте “Бүләк кемгә?” | Балаларның образга керә белү осталыкларын камилләштерү; әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгына соклана белү тәрбияләү. | 1.”Таулар биек таллардан, тал бөресе балланган” тел шомарткычын өйрәтү.<br>2.Хәрәкәтләрне музыка уйнаганда ясарга өйрәтү.<br>3.Дөрес дикция белән сөйләүләренә игътибар итү. | 1.”Иң гүзәл тел-туган тел” китабы, 62-64 битләр.<br>2.”Иң матур сүз” китабы, 361 бит. |
| ***3 нче атна*** | Татар халык әкияте “Бүләк кемгә?” | Балаларның әкиятне сәхнәләштереп уйнау осталыкларын үстерү; рольләрне башкару күнекмәләрен (ишарә, мимика, хәрәкәтләр ясау) камилләштерү. | Әкиятне әти-әниләрнең гомуми җыелышында күрсәтү. | 1.”Иң гүзәл тел-туган тел” китабы, 62-64 битләр.<br>2.”Иң матур сүз” китабы, 172 бит. |

Файдаланылган әдәбият

1. Балалар бакчасында түгәрәкләр: перспектив-тематик планнар, конспектлар: түгәрәк җитәкчеләре, тәрбиячеләр өчен методик ярдәмлек: беренче китап (идея һәм проект авт. Шакирова Т.Р., төз.:Закирова К.В.,Лотфрахманова З.И.).-Казан: “Ак Бүре” нәшр., 2016.-207 б.